ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**22.12.2025**

Зеленодольск шәһәре

**КАРАР**
**№ 3636**

Зеленодольск муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында укучыларны кайнар ризык белән тәэмин итү бәясенең чик күләмнәре турында

Зеленодольск муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында укучыларның балансслы кайнар ризык белән туклану нормаларын үтәүне тәэмин итү максатында Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында укучыларны кайнар ризык белән тәэмин итү бәясенең чик күләмнәрен билгеләргә:
- башлангыч сыйныф укучылары өчен иртәнге кайнар аш бәясе 77 сум 76 тиен, шуның 77сум 76 тиене - субсидия;
- югары сыйныф укучылары өчен иртәнге кайнар аш бәясе 98 сум 70 тиен, шуның 88 сум 00 тиене - ата-ана түләве, 10 сум 70 тиен - субсидия;
- югары сыйныф укучылары өчен ирекле сайлау меню (швед өстәле) бәясе 120 сум 70 тиен, шуның 110 сум 00 тиене - ата-ана түләве, 10 сум 70 тиен- субсидия

2. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының «Зеленодольск муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында укучыларны кайнар ризык белән тәэмин итү бәясенең чик күләмнәре турында» 2024 елның 27 декабрендәге 5454 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.
3. Бу карар 2026 елның 12 гыйнварыннан үз көченә керә.
4. Зеленодольск муниципаль районы Советы аппаратының җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә әлеге карарны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат (http://pravo.tatarstan.ru ) порталына һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат (www.zelenodolsk.tatarstan.ru) сайтына урнаштырырга
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны җитәкче урынбасары- Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты Мәгариф идарәсе башлыгы - Р.В. Афанасьевага йөкләргә.

Җитәкче З.Ф. Хәбибуллин